**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Башлыгы карары**

**10 ноябрь, 2023 ел** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 24 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы,16а адресында урнашкан Сазтамак мәчете бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы,16а адресында урнашкан Сазтамак мәчете бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»
500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- зиратны карап тоту, материал сатып алу һәм койма кору; (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча түләү);

- Сүүткәргеч челтәрләрен һәм су суырту манараларын ремонтлау, тоту, төзекләндерү (артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, килешү буенча түләү)

- Урам яктыртуны карап тоту; (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү)

- Сазтамак авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Сазтамак авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)

- Сазтамак авылы юлларына вак таш җәю ( проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Сазтамак авылындагы чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (материал сатып алу, култыксалы баскычлар урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)

-спорт мәйданчыгын төзү, тоту (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» - ?                «КАРШЫ» - ?

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

5. Байлангар авылы Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы:                И.Ф. Кәримуллин